ПӘНҖЕШӘМБЕ
14
ЯНВАРЬ
1943 ел.
№ 11 (6733)
Аерым номеры 20 тиен.

БАРЛЫК ИЛЛӘРНЕҢ ПРОЛЕТАРИЙЛАРЫ, БЕРЛӘШЕГЕЗ!

КЫЗЫЛ ТАТАРСТАН

ВКП(б) ның ТАТАРСТАН ӨЛКӘ ҺӘМ КАЗАН ШӘҺӘР КОМИТЕТЛАРЫ, ТАССР ВЕРХОВНЫЙ СОВЕТЫ ҺӘМ ХЕЗМӘТ ИЯЛӘРЕ ДЕПУТАТЛАРЫНЫҢ КАЗАН ШӘҺӘР СОВЕТЫ ОРГАНЫ.

Агротехника һәм зоотехника укуларын яхшы итеп оештырырга

Колхозлардагы әзерлекле массовый кадрларның—сабанчыларның, тырмачыларның, чәчүчеләрнең, яровизаторларның, терлекчеләрнең һәм башка шундыйларның күп кенә өлеше Ватан сугышы фронтларына киттеләр. Үткән җәй бу эшләрне нигездә яшьләр, хатын-кызлар һәм гомумән әзерлекләре җитәрлек булмаган кешеләр башкардылар. Дөрес, бу яңа кадрлар да үз өсләренә йөкләнгән бурычларны, гомумән алганда, уңышлы гына үтәп чыктылар. Ләкин, шул ук вакытта, кадрларны алдан әзерләүгә җитәрлек әһәмият бирелмәү нәтиҗәсендә, авыл хуҗалыгы эшләре соңга калып һәм начар сыйфатлы итеп үткәрелгән колхозлар да аз булмады. Ә моның нәтиҗәсе инде көз көне—ындыр табагында бик нык сизелде, кайбер урыннарда уңыш аз чыкты. Аерым колхозларда терлекчелекне үстерү планнарының, терлекләрнең продукция бирүләрен күтәрү буенча заданиеләрнең үтәлешенә кадрларның әзерлексез булулары бик начар йогынты ясады.

Шулай булмый хәле дә юк, чөнки колхоз ул—катлаулы хуҗалык. Ә һәрбер катлаулы хуҗалык, билгеле, теоретик һәм практик яктан яхшы әзерлекле кадрлар булдыруны таләп итә. Менә шуңа күрә дә бьел икмәкне, итне, сөтне, майны һәм гомумән авыл хуҗалыгының башка төр барлык продуктларын ил өчен, фронт өчен мул итеп җитештерү бурычы куелган гаять җаваплы бер вакытта колхозлар өчен югарыда әйтелгән массовый квалификацияле кадрларны әзерләүгә аеруча нык әһәмият бирелергә тиеш.

Тагын шуны онытмаска кирәк, соңгы ике елда безнең Татарстан колхозларында һәм совхозларында күп кенә яңа культуралар игелә башлады. Шикәр чөгендере, тәмәке, күп төрле дару үләннәре — болар барысы да безнең республикабыз өчен яңа культуралар. Ә бу яңа культуралардан хәрби уңыш алу бурычы аларның игелү техникасын яхшылап үзләштерүне таләп итә.

Колхозларда һәм совхозларда агротехника, зоотехника түгәрәкләре югарыда күрсәтелгән кадрларны әзерләүнең төп формасы булып торалар һәм бу түгәрәкләр, әгәр дә аларда эш тиешенчә оештырылса, бигрәк тә аларга белгечләр тарафыннан нык җитәкчелек тәэмин ителсә, бик яхшы нәтиҗәләрне бирәчәкләр.

Менә хәзер колхозларда югары иген уңышы өчен көрәштә хәлиткеч чаралардан кар тоту, басуга тирес чыгару, чәчү орлыкларын чистарту, трнерлау, орлыкларны яровойлаштыруга әзерлек эшләре бара. Терлекчелек фермаларында да иң җаваплы чор—терлекләрнең үрчем бирү чоры башланды. Агротехника һәм зоотехника укуларын, әлбәттә, шул эшләрне үткәрү буенча практик эшкә бәйләп алып барырга кирәк. Үткәрелгән һәрбер практик эшне түгәрәк дәресләрендә җентекләп тикшерергә, киләчәктә ул кимчелекләрнең яңадан кабатланмавы өчен тиешле чараларны билгеләп барырга кирәк.

Агротехника һәм зоотехника укуларын яхшы итеп оештырган колхозлар бездә аз түгел, әлбәттә. Мәсәлән, Кукмара районының «Әсән елга», Кызыл юл районының «Шурабаш», Биектау районының Вахитов исемендәге колхозларында быел кыр эшләрендә катнашырга тиешле колхозчыларның бөтенесе дә агротехника түгәрәкләренә йөриләр һәм үзләре башкарачак эшнең техникасын тырышып өйрәнәләр. Яшьләр җир сөрүдә нагорныйчылар методын кулланырга ныклы әзерлек алып баралар.

Ләкин, гомумән алганда, колхозларыбызда агротехника һәм зоотехника укулары тиешенчә җәелеп киткәне юк әле. Бу кимчелекне кичекмәстән бетерергә кирәк. Һәрбер колхозда һәм һәрбер совхозда агротехника һәм зоотехника укуларын дөрес итеп оештырырга, дәресләрнең алдан әзерләнгән төгәл расписаниеләр белән баруын, кыр эшләрендә катнашырга тиешле барлык колхозчыларның дәресләргә актив катнашуларын тәэмин итәргә кирәк.

РСФСР Верховный Советы Президиумы Указы

РСФСР ХЕЗМӘТ ИЯЛӘРЕ ДЕПУТАТЛАРЫНЫҢ КРАЙ, ӨЛКӘ, ОКРУГ, РАЙОН, ШӘҺӘР, АВЫЛ ҺӘМ ПОСЕЛОК СОВЕТЛАРЫНА САЙЛАУЛАРНЫ КИЧЕКТЕРҮ ТУРЫНДА

РСФСР хезмәт ияләре депутатларының край, өлкә, округ, район, шәһәр, авыл һәм поселок советларына сайлауларны 1943 нче елның декабрена кадәр кичектереп торырга һәм бу советларның полномочиеләрен шул ук срокка озайтырга.

РСФСР Верховный Советы Президиумы Председателе А. БАДАЕВ.
РСФСР Верховный Советы Президиумы Секретаре П. БАХМУРОВ.

Москва, 13 январь, 1943 ел.

МОСКВА, КРЕМЛЬ

Дәүләт Оборона Комитеты Председателе иптәш СТАЛИНГА

Кадерле Иосиф Виссарионович!

СССР Юл Эшләре Халык Комиссариаты работниклары, барлык совет халкы кебек үк, Кызыл Армиянең җиңүле героик һөҗүме белән рухланып һәм явыз дошманны—Германия фашизмын җиңү сәгатен мөмкин кадәр тизрәк якынайту теләге белән сугарылган хәлдә, «Совет тимер юлчысы» исемле бронепоезд төзүгә үзләренең саклык суммаларыннан 1.020.000 сум акчаны шатлык белән керттеләр. Средстволар туплау дәвам итә.

Юл Эшләре Халык Комиссариаты работникларының хезмәт белән тапкан средстволарына төзелгән куәтле бронепоезд явыз дошманны тәмам юк иткәнгә кадәр рәхимсез рәвештә тар-мар итсен.

Кызыл Армия һәм илебез алдында үзләренең җаваплы икәнлекләрен аңлап, тимер юлчылар Сезгә, иптәш Сталин, икенче хәрби кышта тимер юл транспорты Ватан алдындагы үзенең бурычын үтәсен өчен, барлык кирәк нәрсәләрне эшләргә вәгъдә бирәләр.

Юл Эшләре Халык Комиссары А. ХРУЛЕВ.
Юл Эшләре Халык Комиссариаты парткомы секретаре КАЛИНИН.

Юл Эшләре Халык Комиссары иптәш А. ХРУЛЕВКА. Юл Эшләре Халык Комиссариаты парткомы секретаре иптәш КАЛИНИНГА

«Совет тимер юлчысы» исемле бронепоезд төзүгә 1.020.000 сум акча җыйган Юл Эшләре Халык Комиссариаты работникларына минем туганлык сәламемне һәм Кызыл Армиянең рәхмәтен тапшыруыгызны үтенәм.

И. СТАЛИН.

ЛЕНИНГРАД ҺАВА ҺӨҖҮМЕНӘ КАРШЫ ОБОРОНА АРМИЯСЕ

АРМИЯ КОМАНДИРЫ ГЕНЕРАЛ-МАЙОР ИПТӘШ ЗАШИХИНГА ХӘРБИ СОВЕТ ЧЛЕННАРЫ: ЛЕНИНГРАД ШӘҺӘР СОВЕТЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ ПРЕДСЕДАТЕЛЕ ИПТӘШ ПОПКОВКА ГЕНЕРАЛ-МАЙОР ИПТӘШ ВЕРОВКА ПОЛКОВНИК ИПТӘШ ИКОННИКОВКА АРМИЯНЕҢ ПОЛИТБҮЛЕК НАЧАЛЬНИГЫ ПОЛКОВНИК ИПТӘШ ГЕЛЛЕРГА

Һава һөҗүменә каршы СССР оборонасын ныгытуга 1.280.000 сум акча җыйган Ленинград һава һөҗүменә каршы оборона армиясенең сугышчыларына һәм командирларына минем сугышчан сәламемне һәм Кызыл Армиянең рәхмәтен тапшырыгыз.

И. СТАЛИН.

БЕРЕНЧЕ ҺАВА ДЕСАНТЫ ГВАРДИЯ ДИВИЗИЯСЕ ГВАРДИЯ ДИВИЗИЯСЕ КОМАНДИРЫ ГЕНЕРАЛ-МАЙОР КАЗАНКИНГА

«Сталин десантнигы» исемле самолетлар эскадрильяләре төзүгә 1.324.500 сум акча җыйган беренче һава десанты гвардия дивизиясенең сугышчыларына, командирларына һәм политработникларына минем сугышчан сәламемне һәм Кызыл Армиянең рәхмәтен тапшырыгыз.

И. СТАЛИН.

---

92 НЧЕ ЗАВОД ДИРЕКТОРЫ ИПТӘШ ЕЛЯНГА ВКП(б) ҮЗӘК КОМИТЕТЫ ПАРТОРГЫ ИПТӘШ ПРОСКУРИНГА ЗАВОДНЫҢ БАШ ИНЖЕНЕРЫ ИПТӘШ ОЛЕВСКИЙГА ЗАВОД ДИРЕКТОРЫ УРЫНБАСАРЫ ИПТӘШ ЗАККА ЗАВКОМ ПРЕДСЕДАТЕЛЕ ИПТӘШ БЕЛОБРОСОВКА ВЛКСМ ҮЗӘК КОМИТЕТЫ КОМСОРГЫ ИПТӘШ ГУСЕВКА ЦЕХ НАЧАЛЬНИКЛАРЫ ГОРДЕЕВ, ФИЛЬШТЕЙН ИПТӘШЛӘРГӘ ПАРТБЮРО СЕКРЕТАРЕ ИПТӘШ ЛИНЕВКА ЗАВОДНЫҢ СТАХАНОВЧЫЛАРЫ БУХАРЕВ, ЧЕРНОЗУБ, ЗАХАРОВ, ЖУЛОВА, ЦАПЛИН ИПТӘШЛӘРГӘ

Кораллар Халык Комиссариатының 92 нче номерлы, Ленин орденлы заводының «Сталин артиллериясе» исемле артиллерия полклары төзелешенә 4.132.000 сум акча җыйган эшчеләренә, эшче хатын-кызларына, инженерларына, техникларына һәм хезмәткәрләренә минем туганлык сәламемне һәм Кызыл Армиянең рәхмәтен тапшырыгыз.

И. СТАЛИН.

Совет Информбюросыннан

13 нче ЯНВАРЬДАГЫ ИРТӘНГЕ БЕЛДЕРҮ

13 нче январьга каршы төндә безнең гаскәрләр **Донның түбәнге агымы районында, Үзәк фронтта** һәм **Төньяк Кавказда** элекке юнәлешләрдә сугышларны дәвам иттерделәр.

* * *

Сталинградның заводлар районында безнең штурм отрядлары бер участокта шәһәрнең көнбатыш читенә барып чыктылар. Урамнарда, ишек алларында, һәрбер йортта каты бәрелешләр булды. Дошман берберартлы 6 тапкыр контратака ясады. Безнең сугышчылар гитлерчыларның барлык контратакаларын кире кайтардылар һәм бер батальонга якын немец пехотасын кырдылар. Трофейлар кулга төшерелде һәм пленныйлар алынды.

* * *

Донның түбәнге агымы районында безнең гаскәрләр һөҗүмне дәвам иттерделәр. Бер участокта немецлар бик күп санда пехота һәм танклар туплап, безнең частьларга контратака ясаганнар иде. Баштарак дошман танклары бераз гына алга үтә алдылар. Безнең гаскәрләр үз көчләрен яңадан оештырып, гитлерчыларны артка таба алып ташладылар һәм аларны зур югалтуларга дучар иттеләр. Икенче бер участокта безнең частьлар халык яши торган берничә пунктны алдылар. Дошманның 800 гә якын солдат һәм офицерлары, 7 орудиесе юк ителде, 5 танкысы зарарланды һәм яндырылды. 8 орудие, 30 автомашина, күп винтовкалар, сугыш припаслары һәм азык складлары кулга төшерелде.

* * *

Үзәк фронтта безнең гаскәрләр элекке юнәлешләрдә сугышлар алып бардылар. Ржевтан көнбатыштагы районда дошманның ике отряды Н-че часть оборонасының алгы кырыена разведка ясады. Безнең подразделениеләр артиллерия, мылтык һәм пулемет уты белән дошман отрядларын таркаттылар һәм бер өлешен юк иттеләр.

* * *

Төньяк Кавказда совет гаскәрләре, немецларның каршылык күрсәтүен җиңеп, алга киттеләр һәм халык яши торган берничә пунктны алдылар. Н-че укчы часть сугышчылары, танкистлар белән бергә хәрәкәт итеп, дошманны ныгытылган позицияләрдән бәреп чыгардылар. Трофейлар кулга төшерелде һәм пленныйлар алынды. Икенче бер участокта безнең разведчиклар төнлә белән немецлар кулындагы бер тимер юл станциясенә барып чыктылар һәм сугыш припаслары төялгән бер поездны шартлаттылар.

* * *

Өлкән лейтенант Киселев командалыгындагы безнең бер группа самолетлар Краснодар шәһәрендәге дошман аэродромына һөҗүм ясадылар. Очучылар аэродром өстенә кинәт барып чыгып, дошманның андагы самолетларын бомбага тоттылар. Шул ук көнне бу аэродромга тагын берничә һөҗүм ясалды. Немецларның җирдә торган 10 самолеты юк ителде һәм 30 га якын самолеты зарарланды. Шуның өстенә һава сугышында дошманның 2 самолеты бәреп төшерелде.

* * *

Вилейка өлкәсенең берничә районында хәрәкәт итүче партизан отрядлары сугыш хәрәкәтләренең бер ае эчендә дошманның

(Ахыры 2 нче биттә).

СОВЕТ ИНФОРМБЮРОСЫННАН

13 нче ЯНВАРЬДАГЫ ИРТӘНГЕ БЕЛДЕРҮ

(Ахыры. Башы 1 нче биттә).

28 тимер юл эшелонын юлдан чыгарганнар. Һәлакәт нәтиҗәсендә немец-фашист оккупантлар бик күп техникаларын һәм җанлы көчләрен югалтканнар.

* * *

Түбәндә Воронеж өлкәсе, Смаглеевка авылында немец-итальян кабахәтләр эшләгән ерткычлыклар турындагы акт игълан ителә: «Гитлерчылар авылны алганнан соң бөтен халыкны мәйданга куып китерделәр һәм барысын да тәмам чишендереп тентеделәр. Мәйданда тентү барган арада фашист юлбасарлар йортларны, кладовойларны талап йөрделәр һәм барлык кыйммәтле әйберләрне алдылар. Немецлар һәм итальяннар хатын-кызларны тотып алып көчләделәр. Исерек солдатлар төркеме Наталья Лозоваяны үзенең кызларын яклаган өчен, атып үтерде. Немец бандитлар һәм аларның итальян иярченнәре барлык колхозчыларны диярлек таладылар, аларның сыерларын, сарыкларын, дуңгызларын, тавыкларын, продуктларын, шулай ук кием-салымнарын талап алдылар. Гитлерчылар колхозның авыл хуҗалыгы инвентарен юк иттеләр, атларны, мөгезле терлекләрне һәм 250 центнер ашлыкны талап алдылар. Немецлар безнең культура учреждениеләрен туздырдылар, мәктәпләрдәге җиһазларны һәм парталарны яндырдылар, уку кабинетларының җиһазларын юк иттеләр, мәктәп көтепханәсен яндырдылар. Чигенгән чакта бандитлар тулы булмаган ике урта мәктәп бинасын шартлаттылар, ике магазинны һәм колхозчыларның бик күп йортларын яндырдылар.

Без, Смаглеевка авылы колхозчылары, үзебезнең туган Кызыл Армиябезне зур шатлык белән каршы алдык. Безгә 1943 нче яңа елны немец-фашист кабахәтләр изүе астында каршыламыйча, азат совет гражданнары булып каршыларга мөмкинлек биргән совет сугышчыларына рәхмәт әйтәбез». Смаглеевка авылы гражданнарының тапшыруы буенча: Ф. Зябкин, З. Фисенко, А. Бондаренко, П. Иванов, С. Белоганцев, М. Шептухина, А. Половикова, Ф. Пономарева, И. Козинченко, А. Цымбалева, П. Похинский һәм башкалар.

13 нче ЯНВАРЬДАГЫ КИЧКЕ БЕЛДЕРҮ

13 нче январьда безнең гаскәрләр Төньяк Кавказда, һөҗүмне дәвам иттереп, район үзәге Новоселицкоены, халык яшәп торган зур пунктлардан Журавскоены, Китаевскоены, Саблинскоены, Свободныйны, Греческоены, Канглыны, Побегайловскоены, Орбельяновканы, Калаборканы, Ново-Благодарноены һәм тимер юл станциясе Кумагорскийны алдылар.

Донның түбәнге агымы районында һәм Үзәк фронтта безнең гаскәрләр элекке юнәлешләрдә һөҗүм сугышлары алып бардылар.

12 нче январьда безнең авиация частьлары фронтның төрле участокларында немецларның 20 танкысын, гаскәрләр һәм йөкләр төялгән 200 дән артык автомашинасын юк иттеләр яки ватарладылар, 6 артиллерия батареясының утын бастырдылар, 2 тимер юл составын җимерделәр һәм 4 ротага якын дошман пехотасын таркаттылар һәм бер өлешен юк иттеләр.

* * *

Сталинградның заводлар поселогында бер участокта шәһәрнең көнбатыш читенә барып чыккан безнең подразделениеләр үзләре алган позицияләрне ныгыттылар һәм дошманның күп санлы контратакаларын кире кайтардылар. 400 гә якын немец солдатлары һәм офицерлары юк ителде. 10 орудие, 43 пулемет, 4 миномет һәм башка трофейлар кулга төшерелде.

* * *

Донның түбәнге агымы районында безнең гаскәрләр һөҗүмне дәвам иттерделәр. Дошман, тар бер участокка танк һәм пехота частьлары туплап, совет частьларының тылына үтәргә маташып карады. Безнең гаскәрләр гитлерчыларның планнарын җимерделәр һәм аларның барлык контратакаларын кире кайтардылар. Немецлар гаять зур югалтуларга дучар ителделәр һәм берниндидә уңышка ирешә алмадылар. Икенче бер участокта безнең сугышчылар дошманның бер батальонга якын пехотасын, 4 орудиесен; 20 пулеметын һәм 24 автомашинасын юк иттеләр. Трофейлар кулга төшерелде. Шулар арасында 5 орудие, 42 пулемет, бер броневик, берничә җиңел автомобиль һәм мотоцикллар бар.

* * *

Үзәк фронтта, Великие Лукидан көньяк-көнбатыштарак, Н-че часть сугышчылары, безнең позицияләргә атака ясарга маташкан немец пехотасы батальонын авыр югалтуларга дучар иттеләр. Гитлерчылар миномет залплары уты астына килеп керделәр һәм 200 дән артык солдат һәм офицерларын югалтып чигенделәр. Икенче бер участокта безнең подразделениеләр дошманга каршы бик каты сугышта немецларның 6 танкысын яндырдылар; 8 станоклы пулемет, 3 миномет; күп винтовкалар һәм сугыш припаслары кулга төшерделәр.

* * *

Төньяк Кавказда безнең гаскәрләр сугыша-сугыша алга бардылар һәм халык яшәп торып берничә пунктны алдылар. Н-че часть 500 дән артык гитлерчыны юк итте. 10 орудие, 4 автомат пушка, 28 пулемет, 67 автомашина, 50 мең патрон; 4 сугыш припаслары складлы һәм терлекләр көтүе кулга төшерелде. 100 дән артык пленный алынды. Икенче бер участокта дошман пехотасы, 14 танк ярдәме белән, контратакага күчкән иде. Өлкән лейтенант Дорожкин командалыгындагы безнең танкистлар немецларның барлык 14 танкысын юк иттеләр. Шул ук вакытта капитан Киркашвили командалыгындагы подразделение дошман пехотасына кинәт флангтан удар ясады. Кыска гына бәрелештән соң немецлар сугыш кырында 100 дән артык үле гәүдәләрен калдырып, качтылар.

* * *

Украинаның бер группа партизаннары хәрби бурычны үтәгәннән соң үз базаларына кайтып киләләр икән. Гитлерчылар кулындагы бер авыл яныннан узган чакта совет патриотлары кычкыру һәм ыңгырашу тавышлары ишеткәннәр. Партизаннар разведкасы немецларның авыл халкын җәзалауларын хәбәр иткән. Совет патриотлары җәзалаучыларга кинәт һөҗүм ясаганнар һәм 37 дошман солдатын һәм офицерын кырып ташлаганнар.

* * *

Кызыл Армиянең Н-че часте бер группа кызылармеецларны фашистлар пленлыгыннан азат итте. Алар актык чиккә кадәр ябыкканнар һәм җанлы кешеләрдән бигрәк склетларга охшыйлар. Гитлерчылар коллыгыннан азат ителгән С. Оденинцев болай диде: «Без Голубая авылы янындагы лагерьда тордык. Немецлар пленныйларны ачлыктан үтерделәр. Безгә бераз пешкән арыш бирелгән көннәр иң яхшы көннәр дип саналды. Ачлыктан һәм кыйналудан көн саен берничә кеше үлде. Совет гаскәрләре һөҗүмгә күчкәч гитлерчылар безне азык һәм сугыш припаслары төялгән повозкаларга җиктеләр һәм аларны тартып барырга мәҗбүр иттеләр. Аксап баручы пленныйларны немец ерткычлар шунда ук атып үтерделәр. Кызыл Армия безне үлемнән коткарды».

* * *

Немецлар командованиесе гүяки «немец гаскәрләре кулына төшкән совет хәрби пленныйлары башлыча 15 яшьлек малайлардан һәм 60 яшьлек картлардан һәм алардан да картырак кешеләрдән тора» дигән хәбәр тарата. Ялганлауның чигенә барып чыккан гитлерчылар инде бернинди дә яңа нәрсә уйлап таба алмыйлар. 1942 нче елның язында ук бөтен немец-фашист матбугатында «большевиклар сугышка 14 яшьлек кызылармеецларны җибәрәләр» дигән әкият басылып чыккан иде. Шуннан соң бер ел диярлек вакыт үткәч немецлар яңадан шул ук гади шарманкаларын борып җибәрделәр. Гитлерчыларның бу саташуларын тыңлаган һәрбер кешедә ирексездән шушындый сорау туа: әгәр дә Кызыл Армия сафларында 15 яшьлек малайлар һәм бөтенләй картаеп беткән кешеләр сугыша икән, алай булгач андый армия күп миллионлы немец армиясен ничек итеп шундый зур җиңелүгә дучар итә алган соң, немец-фашист гаскәрләрне ничек итеп йөзләрчә километрларга Көнбатышка таба алып ташлый алган соң, ничек итеп Сталинград районында халык яшәп торган 2.000 гә якын пунктны азат итә алган соң, ничек итеп каты сугышларда Нальчикны, Моздокны, Прохладныйны, Георгиевскийны, Пятигорскины, Минеральные Водыны, Кисловодскины, Ессентукины һәм башка күп шәһәрләрне сугышып ала алган соң? Гитлерчыларның хәбәренчә болай килеп чыга, немецлар армиясе шундый хәлгә килеп җиткән, хәтта кызылармеец шинельләре киенгән малайларны һәм картларны күргәч танкларын, орудиеләрен, автомашиналарын һәм складларын ташлап чигенә. Гитлерчыларның тәмам буталып бәткәнлекләре һәм үз ялганнарына үзләре корбан булганлыклары ачык түгелмени? Әгәр дә немецлар командованиесе моннан соң да шул кадәр тырышып ялганлый торган булса, ул чагында аңа немец гаскәрләренең... имчәк балаларына каршы сугышлардагы «уңышлары» турында хәбәр итәргә туры киләчәк.

Татар халкының батыр улы; Н-че авиачастьның очучы-истребителе комсомолец Әхмәтхан Солтанов Сталинград өстендәге һава сугышларында дошманның 5 истребителен атып төшерде һәм бер бомбардировщигын үз самолеты белән бәрдерде. Шуның өстенә, группалап сугышканда, дошманның 18 самолетын юк итте. Рәсемдә: Лейтенант Солтанов.

ТАСС фотохроникасы.

БӨТЕНСОЮЗ СОЦИАЛИСТИК ЯРЫШЫ

Мин икейөзпроцентчы булдым

Заводка килгәндә мин слесарьлык эшен аз гына белә идем. Мине 7 нче разряд слесаре иптәш Поляковка өйрәнчек итеп беркеттеләр. Иптәш Поляков группаның карт һәм тәҗрибәле эшчеләреннән берсе. Ул инде бик күп яшьләрне өйрәтеп чыгарган. Хәзер алар барысы да үзлекләреннән эшлиләр һәм эштә яхшы гына күрсәткечләр бирәләр.

— Яхшы слесарь буласың килсә,—диде ул миңа,— өйрәткәнне игътибар белән тыңла.

Һәм мин аның киңәшен тоттым. Аның сүзе минем өчен закон булды. Ул нәрсә кушса, мин аны үз вакытында төгәл итеп үтәргә тырыштым.

Станок һәм инструментны яхшы белү эшкә өйрәнгәндә бик әһәмиятле. Шуның өчен минем өйрәтүчем моңа нык игътибар итәргә кушты. Мин барыннан да элек, станок һәм инструмент белән эш итәргә өйрәндем. Аларны кадерләп, саклап тотарга, ә инде җиңелчә генә бозылулар булганда үзем көйләргә күнектем.

Мин эш барышында иптәш Поляковның һәрбер хәрәкәтен күзәттем. Ул теге яисә бу детальне эшкәрткәндә һәрбер операция процессын игътибар белән карап тордым. Бу миңа бик нык ярдәм итте. Шуның нәтиҗәсе буларак, мин өйрәнгән вакытта бер генә детальне дә яраксызга чыгармадым, ягъни брак ясамадым.

Иптәш Поляков мине 3 ай өйрәтте. Бу вакыт эчендә мин эштә чыныгу алдым, слесарьлык профессиясен яхшы итеп үзләштердем.

— Хәзер инде син үзлегеңнән эшли аласың,—диде мастер һәм миңа 4 нче разряд биреп аерым эшкә күчерде.

Тырышып өйрәнү бушка китмәде. Үзлегемнән эшләүнең беренче аенда ук мин әйбәт кенә күрсәткечләр бирүгә ирештем: планны арттырып үтәдем, продукциянең сыйфаты яхшы булды.

Хәзер мин икейөзпроцентчы. Гади өйрәнчектән алдынгы эшче булып әверелүем өчен иптәш Поляковка һәм группа коллективына рәхмәт. Мин стахановчы-икейөзпроцентчы дигән исемне намус белән аклармын. Тагын да тырышыбрак эшләрмен, хезмәт җитештерүчәнлеген күтәрермен, эшләп чыгаруны арттырырмын. Канлы фашизмга каршы көрәштә Кызыл Армиягә ярдәм итүдә мин үземнең көчемне кызганмаячакмын. **М. КОЖЕНОВ;**

Н-че заводның мастер Бикжанов группасы эшчесе.

ЭКОНОМИЯ МӘСЬӘЛӘЛӘРЕ БЕЛӘН ҺӘРКӨННЕ ШӨГЫЛЬЛӘНЕРГӘ

Сугыш вакыты законы булган экономия режимы Н-че заводның производство тормышына көннән-көн ныграк керә бара. Узган елның соңгы кварталында экономия мәсьәләләре белән күбрәк шөгыльләнелде һәм шуның нәтиҗәсендә кайбер уңышларга да ирешелде. Электр энергиясен артык тотуга чик куелды һәм шактый күләмдә экономия ясалды.

Начальнигы иптәш Соболевский булган цехта электропроводканы тагын да рациональрак монтажлау методы кертелде. Моның нәтиҗәсендә цехны яктыртуга китә торган барлык электр энергиясенең 10 процентына экономия ясарга мөмкинлек туды. Аннан соң зур көчле ике моторны азрак көчле моторлар белән алыштыру аркасында да 30 киловатт-сәгать электр энергиясенә экономия ясалды.

Начальнигы иптәш Гизмаер булган цех коллективы да узган елның икенче яртысында 19.000 киловатт-сәгать электр энергиясенә экономия ясауга ирешә.

Заводта экономия режимы буенча күргәзмә агитация оештырылды. Завод эшчеләре квартираларында электр энергиясенең күпме тотылуына контроль ясаучы автоматик выключательнең үрнәге аеручә кызыклы. Бу выключательдә энергиянең кайда артык тотылуы билгеле була һәм шунда ук анда ут сүндерелә. Иптәш Голшляегның бу рационаллаштыру тәкъдиме тиздән тормышка ашырыла башлаячак.

Заводта электр энергиясенә экономия ясау резервлары күп әле. Цехларда моторларны тикшереп чыгу аларның тулы көчләренә эшләмәүләрен күрсәтте. Мәсәлән, начальнигы иптәш Ионов булган цехта 5 киловатт белән эшләрлек мотор 12 киловатт-сәгать энергия алып эшли. Яки менә икенче бер цехта 13 киловатт белән эшләүче моторны 7 киловаттлы итеп калдырырга мөмкин.

Электр энергиясенә экономия мәсьәләсе белән кампания рәвешендә генә түгел, һәркөнне шөгыльләнергә кирәк. Электр энергиясенең һәрбер киловатт-сәгате—фронт өчен өстәмә продукция ул.

М. ШВАРЦЕР.

САНИТАРИЯ ОБОРОНАСЫНА ӘЗЕРЛЕК

Саба районының Шекше авылындагы медицина пункты мөдире фельдшерица иптәш Салиха Абдуллина колхозчылар арасында санитария белемнәрен таратуда зур активлык күрсәтә. Аның тырышлыгы белән 5 авылда РОКК ның башлангыч оешмалары төзелде. Иптәш Абдуллина хезмәт күрсәтә торган медицина участогындагы РОКК оешмаларының 250 дән артык члены бар. 300 кеше ГСО значогына норма тапшырды. РОКК оешмалары янында санитария постлары оештырылды.

И. ГАРИПОВ.

Кызыл Армиягә ярдәмне торган саен арттыра барырга!

ЯШЬ ПАТРИОТЛАРНЫҢ АКТИВЛЫГЫ

ШӨГЕР, 13 январь. (Телефон буенча). Район яшьләре һәм комсомолецлары «Татарстан колхозчысы» семле танклар колоннасы төзү фонына 68 мең сум акча җыеп тапшырганнар иде. Иптәш Сталинның котлау телеграммасы аларның патриотик рухларын тагын да күтәрде. Патриотлар радиомитингка катнашучыларның мөрәҗәгатен тыңлагач, иптәш Сталинның телеграммасына җавап итеп, «Татарстан комсомолы» исемендәге самолетлар эскадрильясе төзү өчен средство туплауда актив катнашачакларын әйттеләр.

Керкәле авылы комсомолецлары һәм яшьләре радиомитингны тыңлап бетерү белән үк бу фондка 600 сум акча, Кызыл Армиягә бүләккә 30 пот бәрәңге җыйдылар. Район үзәгенә радиомитингны тыңларга 170 тән артык кеше килгән иде. Радиомитингтан соң җыелыш булды. Җыелышта беренче булып ВЛКСМ ның район комитеты секретаре иптәш Абдуллина чыгыш ясады. Ул самолетлар эскадрильясе төзүгә 2.000 сум акча бирде һәм үзе белән тиңләшергә барлык яшьләрне чакырды. Аның үрнәгендә бер-бер артлы башка яшьләр дә үзләренең саклык акчаларыннан самолетлар эскадрильясе төзүгә средство кертә башладылар. Берничә минут эчендә 5.000 сум акча җыелды.

Яшьләрнең тырышлыгы

Ватан сугышы колхозчы яшьләр арасында патриотлык хисен нык үстерде. Комсомолецлар һәм союздан тыш яшьләр арасында колхозның бердәмлеге һәм яхшы эшләве өчен үзләрен җаваплы итеп санау көчәйде. Колхозның һәрбер эшендә инициатива күрсәтергә тырышучы яшьләрнең саны артты. Шуның өчен дә безнең «Спартак № 1» колхозы (Арча районы) политик һәм хуҗалык эшләре ягыннан нык. Колхоз дәүләткә ашлык тапшыруны ноябрь аенда ук төгәлләде. Язгы чәчүгә әзерлек эшләре дә оешкан төстә алып барыла. Чәчүлек орлык яхшылап чистартып куелды инде. Авыл хуҗалыгы машиналарына ремонт тәмамланды. Басуга 1.400 йөк тирес чыгарылды. Бу эшләрне башкаруда яшьләрнең хезмәте зур булды.

«Татарстан колхозчысы» исемле танклар колоннасы төзүгә акча туплау колхозчылар арасында зур активлык белән барды. Без танклар төзүгә 77.000 сум акча керттек. Бу сумманың 35 меңе яшьләрдән җыелды. Комсомолка иптәш Галимова 1.100 сум; комсомолец Хәмзин 800 сум бирделәр.

Колхозда һәрбер эш фронтка багышлап эшләнә. Дәүләт йөкләмәләрен үтәгәннән соң, Кызыл Армия фондына 588 центнер ашлык, 16 центнер ит бирдек. Комсомолецлар үзләренең шәхси запасларыннан Кызыл Армия өчен ашлык һәм башка продуктлар тапшыру инициативасын күтәреп чыктылар. Иптәш Галимова 6 пот, иптәш Кадирова 3 пот ашлык бирделәр. Бу инициативага колхозчылар да кушылдылар. Кыска гына вакыт эчендә 300 пот ашлык тупланды.

Р. КАДИРОВА,
Комсомолның башлангыч оешмасы секретаре.

Кызыл Армия фондына

БАУЛЫ, 13 январь. (Телефон буенча). Героик Кызыл Армиябезнең зур җиңүләргә ирешүе Баулы районы колхозчылары арасында фронтка ярдәм итү теләген күп тапкырлар арттырды. Колхозчылар үз хуҗалыкларындагы запасларыннан Кызыл Армия фондына ашлык тапшыралар. Киров исемендәге колхоз председателе иптәш Ширшов самолетлар эскадрильясе төзү өчен 20.000 сум акча һәм Кызыл Армия фондына 6 пот ашлык, бер сарык бирде.

Нәриман исемендәге колхоз членнары да бу фондка 39 пот ашлык, 51 пот бәрәңге тапшырдылар. Колхоз председателе иптәш Хәбиров 6 пот ашлык бирде. «Урал» колхозы председателе Батыров һәм колхоз партоешма секретаре Вәлиева иптәшләр 6 шар пот ашлык бүләк иттеләр.

СВОДКА

ТАТАРСТАН АССР МТС ЛАРЫНДА ТРАКТОРЛАРГА РЕМОНТНЫҢ БАРЫШЫ ТУРЫНДА

1943 нче ЕЛНЫҢ 10 нчы ЯНВАРЕНА
(ПЛАНГА КАРАТА ПРОЦЕНТЛАРДА)

МТС лар	Үтәлеш	МТС лар	Үтәлеш	МТС лар	Үтәлеш
1. Нөркәй	94,3	37. Юдино	46,7	74. Этнә	26,0
2. Мөслим	83,0	38. Дөбьяз	45,8	75. Кичү	26,0
3. Ишеево	80,0	39. Актаныш	45,5	76. Арча	25,8
4. Тымытык	75,7	40. Т. Тамак	43,6	77. Әхмәт	25,5
5. Чүпрәле	74,4	41. Чүрибураш	42,6	78. Балтач	25,0
6. Тирсә	72,5	42. Баулы	40,7	79. Биектау	25,0
7. Чокалы	70,9	43. Исәнбай	40,5	80. Тәкәнеш	24,5
8. Бөгелмә	68,1	44. Димитров	40,0	81. Чишмә	24,2
9. Саба	68,0	45. Тәтеш	39,6	82. Ромадан	24,1
10. Алабуга	61,4	46. Кукмара	39,3	83. Черемуховский	24,0
11. Юртыш	60,7	47. Б. Матак	39,2	84. Салман	23,7
12. Тархан	59,0	48. Зирекле	38,4	85. Чаллы	23,6
13. Яниль	56,8	49. Тельман	37,7	86. Карамалы	23,6
14. Кадряк	56,8	50. Яңа Чишмә	37,3	87. Солтан	23,5
15. Сарман	56,6	51. Буа	37,1	88. Макыл	22,6
16. Кызыл йолдыз	55,6	52. Бондюг	35,6	89. Трехозерский	22,6
17. Мөрәле	55,3	53. Куйбышев	35,1	90. Биләр	22,2
18. Октябрь	55,2	54. Кама тамагы	35,3	91. Кызыл юл	22,2
19. Алга	55,0	55. Иске Чишмә	31,8	92. Балык бистәсе	22,0
20. Соколка	54,9	56. Кузнечиха	31,7	93. Минзәлә	21,7
21. Азин	54,8	57. Иске Писмән	31,7	94. Столбище	20,4
22. Норлат	54,8	58. Морт	31,4	95. Каргалы	20,0
23. Зөя	54,8	59. Кәкре елга	31,1	96. Чиябаш	17,5
24. Поповка	53,7	60. Теләче	30,6	97. Иске Тимошкино	17,5
25. Кызыл Чапчак	53,6	61. Алексеевский	30,4	98. Майдан	13,8
26. Беренче Май	53,0	62. Казанбаш	30,3	99. Т. Ялтан	12,1
27. Дәүләки	52,1	63. Шөгер	30,2	100. Ключи	10,3
28. Олы Карилә	52,0	64. Калинин	30,0	101. Тат. Ходяш	8,3
29. Заинский	51,7	65. Питрәч	29,8	102. Мамадыш	8,2
30. Әлмәт	50,0	66. Акташ	29,3	103. Әлки	7,1
31. Мөслим (Чистай)	50,0	67. Әлшн	28,6	104. Зур Поляна	7,0
32. Кузайкино	49,1	68. Буденный	28,1	105. Кошкино	6,5
33. Чистай	49,0	69. Маткавыш	27,6	106. Үзәк	5,9
34. Чыбыклы	48,9	70. Чаллы	27,0		
35. Ютазы	48,0	71. Константиновка	26,9	Барлыгы:	37,3
36. Мәлки	48,0	72. Аксубай	26,8	1943 нче елның 5 нче январена	34,1
		73. Рождественский	26,6		

Әзерлек яхшы

ЧИСТАЙ, 13 январь. (Телефон буенча). «Уракчы» колхозында язгы чәчүгә әзерлек яхшы бара. 12 сабан, 39 тырма, чәчү машиналары һәм культиваторлар ремонтланды инде. Сука камытлары, дилбегәләр, постромка баулары җитәрлек кадәр булдылар.

Ремонтта эшләүче тимерчеләрдән У. Гатин һәм М. Ярмушев иптәшләр көнлек норманы 150—160 процент итеп үтиләр. Камытлар төзәтүче Гумеров һәм Закиров иптәшләр зеруча зур тырышлык күрсәттеләр. Кар тоту, кырга тирес чыгару һәм башка эшләмәләр җыю дәвам итә. Чәчү орлыкларын чистарту шушы көннәрдә тәмам була.

«Новый путь» колхозында да чәчүгә яхшы әзерләнәләр. Басуга 200 йөк тирес чыгарылды, 140 гектар мәйданда кар тотылды.

Ш. ШАКИРОВ.

ХӘРБИ ЭШКӘ ӨЙРӘНҮЧЕЛӘРГӘ ЯРДӘМГӘ

КЫШКЫ МАСКИРОВКА

КЫШ КӨНЕ МАСКИРОВКАДА НИНДИ ҮЗГӘРЕШЛӘР БУЛА

Кыш көне җир өстенең үзенә махсус аерымлыклары була. Сугышчы, үзенең сугышчан практикасында боларны исәпкә алырга тиеш. Тоташ кар катлавы җирдәге һәртөрле чокыр-чакырларны, һәртөрле кечкенә биеклекләрне каплап китә. Мәсәлән, кар белән капланган кырда аяз көнне сугышчының корыч шлемы яки башы 1.500 метрдан, ә инде шинель кигән сугышчы үзе, аякүрә басып килгән чагында, 2.000 метрдан күренә. Әгәр дә җәй көне күләгә сугышчы өчен ышыкланырлык ышанычлы урын булган булса, кыш көне инде күләгә үтә күренә торган була һәм, тик сугышчы маскалаучы халат кигән булганда гына, күләгә аны каплый ала.

Яфраклы урманнар һәм куаклыклар кыш көнендә сугышчының үзен дә, коралларны да юньләп каплый алмыйлар. Кышын, дошманның һавадан һәм җир өстеннән булган һөҗүмнәреннән, тик ылыслы урманга гына яшеренергә мөмкин.

ДОШМАНГА ҮЗЕҢНЕ КҮРСӘТМӘ

Кышын сугышчы үзенең киемнәренең яки корал һәм һәртөрле сугыш кирәк-яракларының төсе белән үзен бик җиңел рәвештә дошман күзенә күрсәтүе мөмкин. Чөнки киемнәр, корал һәм төрле кирәк-яраклар кар катлавының төсеннән аерылып торалар. Корал һәм төрле кирәк-яракларның ялтыравыклы өлешләре (мәсәлән, штык, котелок, һәртөрле каешлар, кышкы зәңгәр күзлек, бинокль, пулемет) кояшлы көнне сугышчыны дошманга сиздертүләре мөмкин; кар белән капланган җир өстендә сугышчы күзгә нык бәрелә. Сугышчының фронт буенча ясаган йөгерешләре һәм хәрәкәте дошманга күренеп торалар.

Атышу вакытында, дошман сугышчыны мылтык тавышы буенча һәм кар тузанының очуы буенча, төнлә исә—утның кабынып китүе буенча сизә ала.

Чаңгы эзләре, сукмаклар, ут яккан урыннар, ашамлык әйберләрнең калдыклары, газета һәм кәгазь кисәкләре, частьның яки подразделениенең кайсы якка таба хәрәкәт итүе һәм аның көчләренең никадәр булуы турында дошманга ориентация бирүләре мөмкин. Шулай ук кар катлавы өстендә транспортның эзләре дә бик ачык күренеп торалар.

СУГЫШЧЫ ҮЗЕН НӘРСӘ БЕЛӘН МАСКАЛЫЙ АЛА

Кыш көне кар катлавы өстендә дошманнан яшеренү өчен, сугышчыларга маскировка киемнәре бирелә. Бу киемнәр: кышкы маскировка халаты, кышкы маскировка костюмы, маскировка җәтмәсе, простынялар, сөлгеләр һәм кул яулыклары,—сугышчыны дошман күзеннән каплыйлар.

Сугышчының буена-сыена сырышып торган маскхалат белән, шуышудан башка, барлык хәрәкәтләрне дә эшләп була. Мондый халатлар артиллериядәге күзәтүчеләргә, орудие расчетларына, снайперларга бирелә.

Маскировка костюмнары белән һәртөрле хәрәкәтне, шул җөмләдән, шуышуны да эшләп була. Мондый костюмнар, иң башлап, разведчикларга, күзәтүчеләргә, чаңгычыларга бирелә. Җәтмәдән файдаланган чакта, аның эченә һәртөрле ак тасмалар яки кәгазь кисәкләре теркәп куела. Мондый җәтмәне өскә ябынып йөрергә дә мөмкин. Шуны яхшы истә тотарга кирәк: бу маскировка киемнәре чиста булсалар гына, алар сугышчыны яшерә алалар. Димәк, землянкаларга һәм ышыклану урыннарына кергәндә, аларны салырга кирәк, окопларда яки ут яннарында исә, сугышчы бу киемнәрнең итәкләрен әйләндереп һәм җиңнәрен сызганып утырырга тиеш.

Мылтыкны һәм кул пулеметын 10—15 сантиметр киңлегендәге ак чүпрәк яки кәгазь лента белән чолгап маскаларга кирәк. Станоклы пулеметларны кыш көне ак буяуга буярга яки өсләренә ак кәгазь ябыштырырга кирәк.

МАСКИРОВКА КАГЫЙДӘЛӘРЕНӘ НЫК ИГЪТИБАР ИТ

Маскировка дисциплинасының төп сорауларын исеңдә тот:

кирәксез һәм артык хәрәкәтләрдән саклан;

дошман безнең позицияләргә каршы ут алып бармаган чагында да окопка яки ышыклану урынына аякүрә баскан килеш якынлашма;

штаблар яки күзәтү пунктлары янында хәрәкәт иткән чакта, үзеңә яңа юллар һәм сукмаклар ясама;

дошман күрерлек урында тәмәке тартма һәм ут якма;

прожектор яктысы астына килеп эләксәң, җиргә ят һәм һич кыймылдама, бу вакытта, иң башлап, корал һәм сугыш кирәк-яракларындагы металл өлешләрен капла;

казып чыгарылган җир, ут якканнан калган күмер, кол һәм төрле чүп-чар белән кар катлавын чүпләмә;

ышыклана торган урыннарда күзәтчелек алып бару өчен эшләнгән ярыклар, атар өчен булган тишекләр һәм ышыклану урынына керә торган җирләр һәрвакыт тирә-яктагы урын кебек итеп маскаланган булырга һәм кара таплар белән тирә-яктагы кар катлавыннан аерылып тормаска тиешләр; моны яхшы күзәтеп торырга кирәк.

Сугышчы, шуны исеңдә тот: маскировка дисциплинасын бозу, ул сине дә, синең иптәшеңне дә, бөтен подразделениене дә куркыныч астына куячак.

АВСТРАЛИЯ ИЛЧЕСЕ В. СЛЕЙТЕР ӘФӘНДЕНЕ ИПТӘШ В. М. МОЛОТОВНЫҢ КАБУЛ ИТҮЕ

1943 нче елның 12 нче январенда Чит Ил Эшләре Халык Комиссары иптәш В. М. Молотов Австралиянең СССР дагы Гадәттән тыш Илчесе һәм Тулы Хокуклы министры В. Слейтер әфәндене кабул итте.

СОҢГЫ ЮЛ

12 нче январьда совет халкы үзенең сөекле кызын—Советлар Союзы Герое Марина Михайловна Раскованы соңгы юлга озатты.

...Постаментта, веноклар һәм чәчәкләр арасында, ал мендәрләргә М. М. Раскованың сугышчан орденнары куелган. Шунда ук аның зур рәсеме. Аны якыннары һәм туганнары шул рәсемдәгечә күрделәр, аңа таныш булмаган, ләкин аны чын күңелдән яраткан меңнәрчә кешеләр аны шул рәсемдәге төсендә белделәр, халыкның хәтерендә ул мәңгелеккә рәсемдәгечә калыр: энергияле, омтылышлы йөз, кыю һәм ачык караш. Аның бөтен тормышы Ватанга багышланган иде. Сугыш кырларында Ватаныбызның язмышы хәл ителгәндә, халкыбызның бәйсезлеге һәм азатлыгы өчен каты сугыш барган көннәрдә ул үзләренең күкрәкләре һәм каннары белән дошманның юлын бикләгән кешеләр арасында булды.

Постамент янында бертуктаусыз почетный каравыл алмашынып тора. Раскованың кәле янында соңгы вахтада ВКП(б) ның Үзәк Комитеты һәм Москва Комитеты секретаре А. С. Щербаков, СССР Совнаркомы председателе урынбасары Первухин, ВКП(б) ның Москва Шәһәр Комитеты секретаре Попов, Москва Шәһәр Советы Башкарма Комитеты председателе Пронин, ВЦСПС секретаре Николаева, Советлар Союзы Маршалы Буденный, Димитров, Советлар Союзы Герое, иптәш Раскованың дусы һәм сугышчан иптәше Гризодубова һәм башка иптәшләр торалар.

15 сәгатьтә Щербаков, Попов, Пронин, Буденный, Димитров, Шахурин, авиация генерал-майоры Никитин, генерал-полковник Артемьев иптәшләр урна куелган катафалкны постаменттан алалар. Кайгылы процессия Кызыл Мәйданны аркылы үтә һәм Ленин мавзолеена таба бара.

Иптәш Пронин кайгы митингысын ача. Ул, ВКП(б) Үзәк Комитеты һәм ССР Союзы Совнаркомы исеменнән сөйләү өчен, иптәш А. С. Щербаковка сүз бирә.

Иптәш Щербаков, безнең халкыбызның иң яхшы сыйфатларын үзендә гәүдәләндергән Марина Раскованың кыска, ләкин данлыклы тормыш юлы турында сөйли.

Аның артыннан микрофон алдына Советлар Союзы Герое иптәш Штепенко килә. Кызыл Армиянең хәрби һава көчләре—Раскованың көрәлдәш батыр иптәшләре исеменнән ул изге совет җирен нык торып сакларга, гитлерчы кабахәтләрне рәхимсез кыйнарга һәм юк итәргә Марина Раскованың кәле янында ант итә.

Соңыннан Советлар Союзы Герое В. С. Гризодубова чыга. Ул үзенең вакытсыз һәлак булган дусы һәм сугышчан көрәштәше турында сөйли. Иптәш Гризодубова совет хатын-кызларына, Раскова кебек булырга, дип ялкынлы чакыру белән мөрәҗәгать итә.

Иптәш Пронин кайгы митингысын ябык дип игълан итә. Щербаков, Попов, Пронин, Димитров, Буденный, Гризодубова иптәшләр мавзолей трибунасыннан төшәләр һәм, урна куелган катафалкны күтәреп; аны Кремль стенасындагы хөрмәтләнгән урынга алып баралар.

Урна куелганнан соң орудиеләрдән өч тапкыр ату тавышы ишетелә һәм кайгы маршлары тавышлары «Интернационал» тавышлары белән алмашыналар. Шул минутта мәйдан өстеннән сугыш самолетлары омтылып очып үтәләр. Сугышларда үзен бетмәслек дан белән каплаган Сталин авиациясе үзенең батыр иптәше Марина Михайловна Раскова белән бәхилләшә.

(ТАСС).

Дәүләт бюджеты проекты уңае белән Рузвельтның конгресска хаты

ВАШИНГТОН, 12 январь. (ТАСС). Рузвельт 1 нче июльдә башлана торган 1943/44 нче яңа бюджет елы өчен бюджет проектын конгрессның раславына кертте. Бюджет суммасы 100 миллиард долларны тәшкил итә. Бу мәсьәлә буенча Рузвельтның конгресска җибәргән хатында болай диелә:

«Үткән елны мин бюджетны тынычлык вакытында экономиканы хәрби экономикага әйләндерү инструменты дип атаган идем. Хәзерге бюджет сугышны алып баруның максималь программасын чагылдыра. Без тоталь сугыш алып барабыз, чөнки безнең яшәвебез куркыныч астында тора. Без, тормышны кадерле итә торган азатлыкны һәм дәрәҗәне гаять зур тырышлыклардан башка саклап калырга өмет итә алмыйбыз. Тоталь сугыш дәһшәтле чынбарлык булып тора. Ул бердәм максат өчен—җиңү өчен—тормышны багышлауны һәм ресурсларны туплауны таләп итә. Тоталь сугыш ул гаять зур конфликттан гыйбарәт. Бу конфликтта һәрбер кеше, милли яктан яшәүне саклап калу максаты белән гомуми тырышлыклар өчен, үзенең тормышы һәм милке иң эффектлы рәвештә файдаланылачагына исәп тотарга тиеш. Сугыш кирәкләре өчен бик нык үсә торган расходлар, җиңүгә ирешү өчен безнең кораллы көчләребезне һәм союзникларыбызны кирәкле булган сугыш кораллары белән тәэмин итәргә карар биргәнлегебезне күрсәтәләр. Пирл-Харбордагы вакыйгалардан соң ук АКШ ның сугыш максатлары өчен ай саен тота торган расходлары 2 миллиард долларга җиткән иде, хәзерге вакытта бу расходлар 6 миллиард доллардан арта, ә 1943/44 нче бюджет елында бу расходлар ай саен уртача 8 миллиард доллардан артыграк булачак. Быелгы бөтен бюджет елы өчен гомуми хәрби расходлар хәзерге көндә 77 миллиард долларны тәшкил итә, киләсе бюджет елында ул 100 миллиард долларга җитәчәк».

Бу хатта Рузвельтның белдерүенә караганда, яңа бюджет, һөҗүм операцияләре өчен кирәкле чикләргә кадәр кораллы көчләрне киңәйтергә мөмкинлек бирәчәк.

Хатта болай диелә: «1940—1942 нче календарь еллар чорында кораллы көчләрнең личный составы артуга да карамастан, АКШ ның промышленность производствосы 46 процентка, ә авыл хуҗалыгы производствосы 15 процентка үсте. 1940 нче елның җәеннән башлап ялланып эшләүчеләрнең һәм кораллы көчләрдә хезмәт итүчеләрнең саны яңадан 10 миллион кешедән дә артты. Боларның 7 миллионы элекке вакытта эшсез йөрүчеләр иде, ә 3 миллионы предприятиеләргә һәм кораллы көчләргә яңадан өстәлгән кешеләр. 1943 нче календарь елында кораллы көчләр өчен һәм хәрби производство өчен өстәмә рәвештә 6 миллион чамасы кеше кирәк булачак. Ике ел ярым эчендә тынычлык вакытындагы промышленностьны хәрби рельсларга күчерү киң күләмдә алып барылды. Ләкин, әгәр дә АКШ бер үк вакытта яңа хәрби промышленность төзелешен бик нык үстерүне үткәрмәгән булса иде, ул чакта без хәзерге көндә билгеләнгән программаны эшкә ашыра алмаган булыр идек». Аннары хатта урта һәм вак предприятиеләрдән тагын да киңрәк күләмдә файдаланырга, планлаштыруны яхшыртырга, бик үк артык кирәк булмаган товарлар җитештерүне кыскартырга, сугыш максатлары өчен һәм гражданнар халкының көн-күрешләре өчен бик кирәкле булган товарлар эшләп чыгаруны арттырырга кирәклеге күрсәтелә. 1941 нче ел белән чагыштырганда, гражданнарның үз кирәкләренә тотыла торган әйберләр уртача 25 процент чамасы кыскартылырга тиеш.

Аннары Рузвельт тоталь сугышны алып бару гражданнар тормышына киң контроль алып баруны таләп иткәнлеген күрсәтә. Ул болай ди: «Кайберәүләр халыкның теге яки бу махсус группасы өстеннән безнең тарафтан контроль ясалуның йомшартылуын теләрләр иде. Алар, бер группа өстеннән контрольнең йомшаруы икенче группалар өстеннән дә контрольне йомшартуга сәбәп булачагын, ә бу хәлнең тормыш өчен кирәкле әйбер бәяләренең кискен рәвештә күтәрелүенә, хәрби тырышлыкларның җимерелүенә һәм сугыштан соң җитди кыенлыклар тудыруга китерәчәген хәтерләреннән чыгаралар. Халыкның барлык группалары өчен экономик стабильләштерү—тоталь сугыш бурычларына җавап бирә торган бердәм политика әнә шундый. Мин конгрессның элекке составларында тегенди яки мондый блокларның булганлыгы турында укыдым. Конгрессның хәзерге составы бер блок белән—милли блок белән чикләнсен».

1943/44 нче бюджет елында гамәлдәге закон буенча күздә тотылган гомуми һәм махсус доходларның суммасы 35 миллиард доллар, ягъни 1939/40 нчы бюджет елына караганда 6 тапкырга якын артыграк итеп билгеләнә. Расходлар тагын да кызурак темп белән үсә, шуңлыктан налоглар салу һәм сак-лык суммалар табу юлы белән 1943/44 нче бюджет елында кимендә 16 миллиард доллар өстәмә сумма тупларга омтылырга кирәк. Хәзерге бюджет елы ахырында АКШ ның дәүләт бурычы 135 миллиард долларга җитә, ә 1944 нче елның 30 нчы июненә ул 210 миллиард долларга якын булачак. Хатның ахырында болай диелә: «Мондый бурыч түләнә алачак һәм түләнер. Безнең илебез кредитны тулысынча түли алырга сәләтле».

РУМЫНИЯДӘ ЭЧКЕ ХӘЛЛӘРНЕҢ КИСКЕНЛӘШҮЕ

ӘНКАРӘ, 12 январь. (ТАСС). Румыниядә эчке хәлләр һаман кискенләшә бара. Хөкүмәтнең политик темаларга, бигрәк тә фронттагы хәл турында һәртөрле сөйләшүләрне яки дискуссияләрне тыя торган боерыгы игълан ителгән. Мондый сөйләнүләр яки дискуссияләр өчен бик авыр җәзалар һәм хәтта үлем җәзасы биреләчәк. Аннан соң шул ук боерыкта илнең эчке кыенлыклары турындагы мәсьәләләрне тикшерү сугыш вакыты законнарын бозу дип каралачак, диелә.

Бухарестта, Крайовада, Плоештида һәм Румыниянең башка күп шәһәрләрендә Антонеску өеренә оппозиция карашында булуда һәм сугышка каршы настроениеләрдә шикләнелгән бик күп кешеләрне кулга алу дәвам итә. Румыния төрмәләре тулганлыктан Антонеску приказы буенча берничә яңа концентрация лагере төзелгән. Бу лагерьлар гестапо агентларының махсус күзәтүе астында торалар. Бу лагерьларда коточкыч режим кертелгән.

Швеция полициясендә фашистларның җәзасыз калулары

СТОКҺОЛЬМ, 12 январь. (ТАСС). Моннан элек хәбәр ителгәнчә, үткән елның 27 нче декабрендә Стокһольмда ТАСС ның Стокһольм бүлеге мөдире Лисингә карата хулиганлык чыгышы эшләнүгә, аның законсыз кулга алынуына һәм полицейскийлар тарафыннан кыйналуына каршы СССР ның Стокһольмдагы миссиясе тарафыннан Швециянең чит ил эшләре министрлыгына протест белдерелгән иде.

Швеция ягыннан бу күңел чиркандыргыч эшне тикшерергә һәм аңлатма бирергә совет миссиясенә вәгъдә ителде. Шул вакыттан бирле тикшерүне тәмам итү һәм полициянең гаепле чиновникларына җәза бирү өчен бөтенләй җитәрлек озын срок үтте инде. Ләкин тикшерү турында да, гаеплеләргә җәза бирү турында да берни дә ишетелгәне юк. Мәгълүм булганча, бу эш буенча Швеция властьларының бөтен чаралары тик шуның белән генә чикләнде: Швециянең чит ил эшләре министрлыгы полициянең бу хәрәкәтләре буенча һәм шул уңай белән Швециядә гитлерчылар тарафыннан чыгарыла торган «Дагпостен» газетасының үз-үзен тотуы өчен совет миссиясенә кызганыч белдерде.

Лисингә карата полицейскийлар тарафыннан эшләнгән бу кабахәт эшне тикшерүдә Швеция властьларының акрын кыймылдаулары һәм хулиганлык чыгышы ясауда гаепле кешеләрнең шушы вакытка кадәр җәза алмыйча калулары, бигрәк тә Швеция полициясенә фашистлар яклы элементларның кереп оялаулары һәм Швеция полициясендә гитлерчы гестапо методларының киң күләмгә җәелү факты Швеция җәмәгатьчелегенең төрле даирәләрендә һәм күп кенә чит ил журналистлары арасында гаҗәпләнү тудыра.

ЮГОСЛАВИЯДӘГЕ ХӘЛ

Оккупантлар тарафыннан таланган Югославия халкы материаль яктан авыр мохтаҗлыклар кичерә. Көненә 150 грамм икмәк бары эшләүче кешеләргә генә бирелә, аларның семья членнары ачлыкка дучар ителгән. Икмәк пешерә торган он 80 процентка төрле ясалма нәрсәләрдән тора. Ачлык нәтиҗәсендә үлүчеләр һәм туберкулез белән авыручылар саны арта.

Партизаннар хәрәкәте көннән-көн көчәя. Югославия патриотлары немец һәм итальян басып алучыларга каршы уңышлы көрәш алып баралар. Югославиядә оккупантларның хәле бик авыраеп бара. Бу турыда фашистларның «Пополо д' Италиа» газетасы болай дип яза: «Бу сугыш бик күңелсез эш. Монда хәтта фронт линиясе турында сөйләргә дә мөмкин түгел. Дошман кинәт килеп чыга һәм кинәт юк була. Ул бер урында бик көчле удар ясаганнан соң шунда ук икенче урында удар ясау өчен күренә. Дошман һәркайда да бар. Атмосфера һәр вакыт кискен, куркынычлы хәлләр белән тулган».

Партизаннар халык яши торган пунктларны оккупантлардан бер-бер артлы азат итәләр. Азат ителгән районнарда партизаннарны корал белән тәэмин итеп торучы хәрби промышленность төзелә. Шулай ук анда оккупантлар басып алган районнардагы халык арасында киң пропаганда алып баручы газеталар чыгарыла.

Югославия халкының нык каршылык күрсәтүеннән котырынган гитлерчылар террорны көчәйтәләр һәм һичбер түзәргә мөмкин булмаслык оккупация режимы урнаштыралар. Белградта немецлар полициясе күпләп кулга алуларны дәвам иттерә. Оккупантлар илнең күп шәһәрләрендә гадәттән тыш чараларны көчәйттеләр. Крушевацта халыкның шәһәр үзәгендә һәм зур урамнарда һәртөрле күңел ачып йөрүләре тыелган. Загребта урамнарда көн саен тентүләр һәм массовый облавалар үткәрәләр. Һәрбер облава вакытында дистәләрчә кешеләр кулга алына. Кулга алынучыларны бик каты җәзалыйлар, аларның күпләре бу җәзалаулардан үлә. Гитлерчыларның «Ново Хрватска» газетасы, оятсыз рәвештә, «Без үзебезнең кешелексезлегебез белән бөтен дөньяда дан казандык» дип яза. Газета, Югославиядә «киләчәктә дә хәзерге режимга каршы көрәшүчеләрнең башлары киселәчәк» дип кисәтү ясый. (ТАСС).

Җаваплы редактор урынбасары
ГАЛИМ РЯБКОВ.

Редакциянең телефон номерлары: җаваплы редактор—АТС 73—27. редактор урынбасары—АТС 76—29. секретарь—АТС 79—29. Партия тормышы бүлеге 14—75. промышленность-транспорт һәм хатлар бүлеге АТС 75—55, авыл хуҗалыгы бүлеге АТС 76—14, типография 36—60.

ПФ612 «КРАСНАЯ ТАТАРИЯ» һәм «КЫЗЫЛ ТАТАРСТАН издательствосының АЛЕКСАНДРОВ ИСЕМЕНДӘГЕ ТИПОГРАФИЯСЕ № Заказ 87